**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре (16д.)**

**1.Кол Гали кайчан һәм кайда туган?**

а) 1183 нче елда борынгы Кашан шәһәрендә;

ә) 1213 нче елда Мисырда;

б) 1100 нче елда Болгарда.

**2. Хәзерге көндә аның кайсы әсәре билгеле?**

а) “Йосыф – Зөләйха”;

ә) “Кыйссаи Йосыф”;

б) “Йосыф китабы”.

**3.Бу әсәрнең язылуына күпме вакыт үткән?**

а) 3 гасыр;

ә) 5 гасыр;

б) 8 гасырдан артык.

**4. «Кыйссаи Йосыф» китабы турында кайсы галим өйрәнгән?**

а) Нурмөхәммәт Хисамов;

ә) Хатыйп Миңнегулов;

б) Фәридә Хәсәнова.

**5. «Йосыф кыйссасы» исемле балет либреттосын кем язган?**

а) Мөхәммәт Мәһдиев;

ә) Ренат Харис;

б) Илдар Юзеев.

**6. Йосыф кем ул?**

а) Якуб пәйгамбәрнең улы, бик чибәр, зирәк бала;

ә) гаиләдәге өлкән бала;

б) бик чибәр, акыллы, зирәк бала.

**7. Агалары Йосыфка карата нинди начарлык эшли?**

а) үзләре белән сахрага алып бармыйлар;

ә) Йосыфны кол итеп сатып җибәрәләр;

б) кыйныйлар.

**8. Ник Йосыф туганнары белән көрәшми?**

а) бик акыллы, чибәр һәм зирәк була;

ә) абыйларын яратмый;

б) аларны бик ярата.

Ачкыч

1. А
2. Ә
3. Б
4. А
5. Ә
6. А
7. Ә
8. Б

**Бәяләү**

**7-8 балл – “5”ле**

**6 балл – “4”ле**

**4-5 балл – “3”ле**

**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре (17д.)**

**1. «Кыйссаи Йосыф» — төрки поэзиядә ике тиң гүзәлне үзәккә куеп тасвирлаган беренче әсәр» дигән юлларны кем язган?**

а) Нурмөхәммәт Хисамов;

ә) Зәет Мәҗитов;

б) һәр галим.

**2. Дәреслекнең икенче кисәгенең ничәнче битләрендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре бирелгән?**

а) 28—33 нче битләрдә;

ә) 30—35 нче битләрдә;

б) 31—42 нче битләрдә.

**3. 29 нчы биттә ничә сүзгә аңлатма бирелгән?**

а) 10 сүзгә;

ә) 12 сүзгә;

б) 14 сүзгә.

**4.Йосыфның төш күрүен агаларына кем җиткерә?**

а) Ибне Ямин;

ә) үги кыз;

б) Яһүдә.

**5. Якуб пәйгамбәр улының төшен ничек юрый?**

а) киләчәктә пәйгамбәр булачагын, туганнарының аңа хезмәт итәчәген әйтә;
ә) тыныч кына яшәрсең, ди;

б) зур бер илдә торачаксың, ди.

**6.Бу поэма ничә өлештән тора?**

а) өч өлештән;

ә) дүрт өлештән;

б) биш өлештән.

**7.Бу әсәрне халык укыймы?**

а) әйе, яратып укый;

ә) юк, әсәр кызыксыз;

б) әсәр белән кызыксынмыйлар.

**8. Йосыфны абыйлары нигә сатып җибәрә?**

а) көнләшеп;

ә) үтерергә җәлләп;

б) ялганнары ачылудан куркып.

**Ачкыч**

1. А
2. А
3. Б
4. Ә
5. А
6. А
7. А
8. А

**Бәяләү**

**7-8 балл – “5”ле**

**6 балл – “4”ле**

**4-5 балл – “3”ле**